**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Актаныш муниципаль районының 2018 елның 13 сентябрендәге ПР-226 номерлы «Актаныш муниципаль районы буенча психологик-педагогик комиссия турында» Башкарма комитет карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 42 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының 10.01.2014 ел, № 2174/14 хатлары, «Психологик-медик-педагогик комиссияләр эшчәнлеген камилләштерү турында» гы 23.05.16 ел, № ВК1074/07 һәм РРФ МО хатлары, мәктәпкә адаптация кыенлыклары кичергән балаларны дифференциацияләнгән укытуны тәэмин итү максатларында, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 сентябрендәге ПР-226 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы буенча психологик-медик-педагогик комиссиясе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 пунктның 2 абзацында «укытучы-дефектолог» сүзләрен «укытучы-дефектологлар (тиешле профиль буенча: олигофренопедагог, тифлопедагог, сурдопедагог)» сүзләренә алмаштырырга;

2) 19 пунктның 3 абзацында «яисә, тапшыру турында хәбәр итеп, почта аша җибәрелә» сүзләрен өстәргә;

3) 14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Комиссия түбәндәге документлар алып бара:

а) балаларны тикшерүгә яздыру журналы;

б) тикшерү узган балаларны исәпкә алу журналы;

в) тикшерү узган бала картасы;

г) баланы тикшерү беркетмәсе (алга таба - беркетмә).».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көненнән http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында үз көченә керә.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев